ГЛАВА МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

**Карар** **Постановление**

№ 237 от « 11 » 12 2024 г.

Район Башлыгының 2015 елның 3 июнендәге 049 нчы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында (07.05.2020 ел, №032; 20.07.2022 ел, № 133; 16.12.2022 ел, № 242, 15.09.2023 ел №145; 25.10.2024 ел №220 карарлардагы үзгәрешләр белән)

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» 2010 елның 30 июлендәге № 60-ТРЗ номерлы, «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 25 октябрендәге 86-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары нигезендә к а р а р б и р э м:

1. Мамадыш муниципаль районы Башлыгының 2015 елның 3 июнендәге «Мамадыш муниципаль районы җирле үзидарә органнарының административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлары исемлеген билгеләү турында» 049 нчы карары (алаг таба- Карар) белән расланган Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлегенә түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1) 3.2 статьяда:

а) 1 өлешнең икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«кисәтү ясала яисә гражданнарга - өч мең сумнан алып дүрт мең сумга кадәр; вазыйфаи затларга – егерме биш мең сумнан алып кырык мең сумга кадәр; юридик затларга йөз мең сумнан алып ике йөз илле мең сумга кадәр күләмдә административ штраф салына.»;

б) 2 өлешнең икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гражданнарга – дүрт меңсумнан алып биш мең сумга кадәр; вазыйфаи затларга – кырык мең сумнан алып илле мең сумга кадәр; юридик затларга- биш йөз мең сумнан алып бер миллион сумга кадәр административ штраф салына.»;

в) 3 өлешнең икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

000266

«гражданнарга – өч мең биш йөз сумнан алып  дүрт мең биш йөз сумга кадәр; вазыйфаи затларга – утыз биш мең сумнан алып  кырык биш мең сумга кадәр; юридик затларга-өч йөз мең сумнан алып  дүрт йөз илле мең сумга кадәр күләмдә  административ штраф салына»;

г) 4 өлешнең икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гражданнарга – дүрт мең биш йөз сумнан алып  биш мең сумга кадәр; вазыйфаи затларга – кырык биш мең сумнан алып  илле мең сумга кадәр; юридик затларга-алты йөз мең сумнан алып  бер миллион сумга кадәр күләмдә административ штраф салына.»;

2) 3.16 статьеяда:

а) исемне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Статья 3.16. Түләүле муниципаль парковкалардан (парковка урыннарыннан) файдалану тәртибен бозу»;

б)беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Транспорт чарасын түләүле муниципаль парковкага (парковка урынына) урнаштырган өчен түләмәүдә, яисә муниципаль хокукый актта билгеләнгән күләмнән кимрәк түләү кертүдә, яисә парковкадан файдаланган өчен муниципаль хокукый актта билгеләнгән түләү срогыннансоңрак түләү кертүдә чагылган түләүле муниципаль парковкалардан (парковка урыннарыннан) файдалануның  муниципаль хокукый акт белән билгеләнгән тәртибен бозган өчен -».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://mamadysh.tatarstan.ru// веб адрес буенча бастырып чыгарырга һәм Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә  йөкләргә.

Муниципаль район
Башлыгы                                                    В.И.Никитин

Муниципаль район Башлыгының
«11» 12 2024 ел,
№237 карарына кушымта

| статья № КоАП РТ | статьяның исеме | җаваплылык/ штрафлар | Хокук бозу субъекты | Җәза чаралары | Протоколны караучы орган | Беркетмәләр төзергә вәкаләтле затлар |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **3.2 ст. Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексы** | **Урам сәүдәсен һәм халыкның күңел ачуына бәйле булган хезмәтләр күрсәтүне оештыру тәртибен бозу** | **Кисәтү яисә штраф** | Граждан нар | **Кисәтү яисә штраф 3000 сумнан алып 4000 сумга кадәр** | **Мамадыш муниципаль районының административ комиссиясе**<br><br>**Контакт өчен мәгълүмат: 422190 ТР, Мамадыш ш., М. Җәлил ур., 23/33 й., тел. 8 (85563) 3-31-26** | - Муниципаль район Башкарма комитеты житәкчесе урынбасары (икътисад мәсьәләләре буенча);- Муниципаль район башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге башлыгы;<br>- Муниципаль район башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге баш белгече;<br>- Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының хокукый эш бүлеге баш белгече (җәмәгать тәртибен саклауны һәм җәмәгать иминлеген оештыру буенча),<br>- Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының хокукый эш бүлеге әйдәүче белгече (торак секторында хокук бозуларны профилактикалау һәм индивидуаль профилактик йогынты чараларын куллану инспекторлары) |
| | | | Вазифаи зат | **штраф 25.000 мең сумнан алып 40 .000 сумга кадәр** | | |
| | | | Юридик зат | **штраф 100.000 сумнан алып 250 .000 сумга кадәр** | | |
| | | **2. 1 өлештә күрсәтелгән шул ук гамәлләрне ел дәвамында кабат кылган өчен** | Граждан нар | **Кисәтү яисә штраф 4000 сумнан алып 5000** сумга кадәр | | |
| | | | Вазифаи зат | **штраф 40.000 сумнан алып 50 .000 сумга кадәр** | | |
| | | | Юридик зат | **штраф 500.000 сумнан алып 1000 .000 сумга кадәр** | | |
| | | **3. Стационар булмаган сәүдә** | Граждан нар | **штраф 3500 сумнан алып 4500 сумга кадәр** | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | **объектларын урнаштыру тәртибен (схемасын) бозган өчен** | Вазифаи зат | **штраф 35.000 сумнан алып 45.000 сумга кадәр** | | |
| | | | Юридик зат | **штраф 300.000 сумнан алып 450.000 сумга кадәр** | | |
| | | **4. Әлеге статьяның 3 өлешендә каралган гамәлләрне ел дәвамында кабат кылган өчен** | Гражданнар | **Штраф 4500 сумнан алып 5000 сумга кадәр** | | |
| | | | Вазифаи зат | **Штраф 45.000 сумнан алып 50.000 сумга кадәр** | | |
| | | | Юридик зат | **Штраф 600.000 сумнан алып 1000.000 сумга кадәр** | | |
| **3.16. ст. Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексы** | **Транспорт чараларын түләүле муниципаль парковкада (парковка урыннарында) урнаштырган өчен түләмәү** | Административ штраф | **Гражд.** | **Штраф 2500 сум** | **Мамадыш муниципаль районының административ комиссиясе**<br><br>**Контакт өчен мәгълүмат: 422190 ТР, Мамадыш ш., М. Җәлил ур., 23/33 й., тел. 8 (85563) 3-31-26** | - Муниципаль район Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы;<br>- Муниципаль район Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге баш белгече;<br>- Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының хокукый эш бүлеге баш белгече (җәмәгать тәртибен саклауны һәм җәмәгать иминлеген оештыру буенча),<br>- Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының хокукый эш бүлегенең әйдәп баручы белгече (торак секторында хокук бозуларны профилактикалау һәм индивидуаль профилактик йогынты чараларын куллану буенча инспекторлар). |

Муниципаль район Советы аппараты җитәкчесе — В.Н.Фәизов